КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 8 июнь г.Казань № 357

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2015 ел, 29 гыйнвар, 48 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2015 ел, 29 гыйнвар, 48 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 7 февраль, 69 нчы, 2016 ел, 28 октябрь, 793 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карарның преамбуласында һәм Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмәнең 1 пунктында «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Россия Федерациясе субъектының лицензия комиссиясен төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе турындагы методик күрсәтмәләрне раслау хакында» 2014 ел, 28 октябрь, 658/пр боерыгы нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан А.В.Песошинны чыгарырга;

комиссия составына Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\357.docx